**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«30» март 2026 ел № 37

Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә мәктәп яны лагерьларын кабул итү комиссиясен булдыру турында

МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге»нең 2026 елның 10 мартындагы 117 номерлы хатын карап, балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, балалар һәм яшьләр ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы, «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2025 елның 22 сентябрендәге 725 номерлы карарлары, Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 2 маартындагы 29 номерлы «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «2023-2027 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 181 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары, «2023-2028 елларга Теләче муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялы» 3 номерлы ярдәмче программасы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елда Теләче муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә мәктәп яны лагерьларын кабул итү буенча район комиссиясен (алга таба текст буенча - Комиссия) төзергә һәм аның составын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Теләче муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә мәктәп яны лагерьларын әзерләү эшен гамәлдәге кануннар нигезендә оештырырга.

3. Комиссиягә 2026 елның 25 маеннан 29 маена кадәр Теләче муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә мәктәп яны лагерьларын кабул итү эшен оештырырга, үз эшчәнлеген гамәлдәге законнар кысаларында башкарырга, нәтиҗәләр буенча һәр мәктәп яны лагере буенча актлар төзергә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Кушымта

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«30» 03 2026 № 37
карары белән раслаган

Теләче муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә мәктәп яны лагерьларын кабул итү буенча комиссия

Комиссия рәисе:

Гыйниятуллин Д.С. - Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары.

Комиссия рәисе урынбасарлары:

Ибраһимов З.З. - Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы;

Карпова Н.В. - МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» башлыгы.

Комиссия әгъзалары:

Хәкимуллин Л.М. - Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының КЭИһПЭ Саба һәм Теләче муниципаль районнары буенча РКЭБһПЭ баш инспекторы (килешү буенча);

Исмәгыйлева Р.М. - Теләче район үзәк хастаханәсе дәүләт автономияле сәламәтлек саклау учреждениесе педиатры (килешү буенча);

Әхтәмҗанова А.А. - Россия ЭЭМ Теләче районы буенча УУП и ПДН бүлегенең ПДН баш инспекторы (килешү буенча);

Әхвәрова Г.М. - МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» башлыгының тәрбия эше буенча урынбасары;

Әхмәтвәлиева Г.Ф. - МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»нең тәрбия эше һәм өстәмә белем буенча методисты;

Салахиева Г.Р. - балалар иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек итү һәм тәрбия буенча директорлар киңәшчеләренең муниципаль координаторы.